ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

21. 11. 2022 г.Мензелинск № 385

**«Өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Минзәлә муниципаль районы гражданнарының гаиләләренә ярдәм чаралары турында» Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитетының 03.10.2022 № 334 карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 21.09.2022 ел, №647 Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә, «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында» 20.10.2022 ел, № 1122 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Карары нигезендә, «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль законнар «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары»Федераль законы, 29.12.2012 №273 "Россия Федерациясендә мәгариф турында" Федераль закон, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында» 09.11.2022 № 1903/22 боерыгы белән, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Уставы белән, өлешчә мобилизацияләү буенча, контракт буенча «Тимер» һәм «Алга»исемле батальоннарга хәрби хезмәткә чакырылган Минзәлә муниципаль районы гражданнары гаиләләренә социаль ярдәм күрсәтү максатларында, Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР ЧЫГАРА:**

1. «Өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Минзәлә муниципаль районы гражданнарының гаиләләренә ярдәм чаралары турында» № 334 03.10.2022ел Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә.

2. 1.1 пунктын түбәндәге редакциядә чыгарырга:

- 2022 елның 1 октябреннән өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Минзәлә муниципаль районы мәгариф оешмаларында балаларны карап торган һәм тәрбияләгән өчен ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) алына торган түләүдән азат итәргә.

3. 1.1.1 пунктчасын өстәргә һәм аны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- 2022 елның 1 декабреннән «Тимер» һәм «Алга» исемле батальоннарына хәрби хезмәткә чакырылган Минзәлә муниципаль районы мәгариф оешмаларында балаларны карап торган һәм тәрбияләгән өчен ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) алына торган түләүдән азат итәргә.

4. 1.2 пунктын түбәндәге редакциядә чыгарырга:

- 2022 елның 28 ноябреннән «Тимер» һәм «Алга» исемле батальоннарына өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылганнарның балаларына ике тапкыр түләүсез туклану (иртәнге һәм төшке аш) оештырырга.

5. 2.3 пунктчасын өстәргә һәм аны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- «Минзәлә муниципаль районының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге» МКУга «Тимер» һәм «Алга»исемле батальоннарга контракт буенча чакырылганнарның балаларына ташламаларны билгеләнгән ташламалар буенча башкарырга.

6. 3.3 пунктчасын өстәргә һәм аны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- «Минзәлә муниципаль районының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге» МКУга «Тимер» һәм «Алга»исемле батальоннарга контракт буенча чакырылганнарның балаларына ташламаларны билгеләнгән ташламалар буенча башкарырга.

7. 3.4 пунктчасын өстәргә һәм аны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- Минзәлә шәһәре буенча җәмәгать транспортына өлешчә мобилизацияләү, «Тимер» һәм «Алга»исемле батальоннарына контракт буенча хәрби хезмәткә чакырылганнарның балаларына транспорт картасы (йөрү билеты) бирергә.

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Н.Г. Бикеевага йөкләргә.

Җитәкче М. Р. Кәримов

Республика Татарстан Мензелинский муниципальный район · Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы · ОГРН 1061682000380 · р 06 92/09 · Исполнительный комитет Мензелинского муниципального района · ИНН 1628006341